СОВЕТ
СТАРОТЯБЕРДИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ИСКЕ ТӘРБИТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

01 октябрь 2019 ел. Иске-Тәрбит авылы № 25

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Иске Тәрбит авыл җирлеге
Иске-Тәрбит торак пунктында
үзара салым кертү мәсьәләсе буенча
гражданнар җыены билгеләү турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Уставының 22 нче маддәсенә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Советына туры китереп, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге карар кабул итте:

1. 2019 елның 3 октябрендә 14 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Иске Тәрбит авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2019 елның 8 октябрендә 14 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Иске Тәрбит авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 2019 елның 11 октябрендә 14 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Иске Тәрбит авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.
4. 2019 елның 15 октябрендә 14 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Иске

Тәрбит авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар жыенының дүртенче этабын 14 сәгать 00 минутка билгеләргә

5. Гражданнар жыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2020 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске Тәрбит авыл жирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча жирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

а) жирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- авыл жирлеге торак пунктларында санкцияләнгән һәм санкцияләнмәгән чүплекләр территорияләрен чистарту;

- материаллар сатып алып күперләрне ремонтлау;

б) жирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

- материаллар сатып алып, су челтәрләрен ремонтлау;

в) жирле автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;

- торак пунктлар чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту

г) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;

- зиратларны чистарту һәм төзекләндерү, материаллар алу белән;

« ӨЧЕН» КАРШЫ »

6. Әлеге карарны Иске Тәрбит авыл жирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл жирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет Рәисе,<br>Иске Тәрбит авыл жирлеге башлыгы: В.Г.Тимофеев